## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

10 октябрь 2023 ел. № 4

2024 елда ТР Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең

Кече Сон торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегендә гражданнар җыены

Карар:

1. 2024 елда үзара салымны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Кече Сон торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнардан тыш, 800 (Сигез йөз) сум күләмендә кертергә

2. Алынган акчаларны җибәрү.:

-Кече Сон торак пунктында Гагарин, Г. Тукай урамнарына юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, ком, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Кече Сон торак пунктында урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру;

- Кече Сон торак пунктында җирле әһәмияттәге юлларны грейдлау һәм кардан чистарту.

3. Җыенның әлеге карарын Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

http://mamadysh.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында ( pravo.tatarstan.ru.)

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге башлыгы М. Ф. Сәләхов